ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

с. Верхний Услон

28.06.2020 №380

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 мартындагы 176 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен билгеләү турында» 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исемлеген алып бару тәртибе турында» 2009 елның 19 августындагы 48-540 номерлы карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлегенә 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В. С. Тимиряев

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_____» ____________ № ______
карарына

1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрольнең һәм аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге

| № т/б | Муниципаль контроль төренең атамасы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле исеме (урнашу урыны, телефон) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, муниципаль норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Муниципаль җир контроле | «Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Югары Ослан авылы, Медгородок ур., 1, Тел. 2-19-35 | Россия Федерациясе Җир кодексы.<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында «Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы.<br>Татарстан Республикасы Җир кодексы.<br>«Югары Ослан муниципаль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | районы территориясендә җирләрне файдалануны муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Советының 9-82 номерлы карары. |
| 2 | Муниципаль торак контроле | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, ТКХ, элемтә һәм энергетика бүлеге, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18, тел. 2-23-43 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы.<br>Россия Федерациясе Торак кодексы.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2006 елның 21 апрелендәге 233 номерлы РФ Хөкүмәте карары.<br>«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы РФ Хөкүмәте карары.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында «Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы РФ Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы.<br>«Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 18 июлендәге 1036 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | номерлы «Югары Ослан муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча комиссия төзү һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 1336 номерлы карары |
| 3 | Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлеге буенча дәүләт контроле һәм күзәтчелеге | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, ТКХ, элемтә һәм энергетика бүлеге, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18, тел. 2-23-43 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы.<br>Россия Федерациясе Торак кодексы.<br>«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары.<br>«Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисап |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тотуы турында» 2005 елның 27 октябрендәге 645 номерлы РФ Хөкүмәте карары.<br>«Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» .2006 елның 24 апрелендәге 233 номерлы РФ Хөкүмәте карары.<br>«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы РФ Хөкүмәт карары.<br>«Өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды «Гавами - хокук компаниясе турында» 2017 елның 7 октябрендәге 1231 номерлы РФ Хөкүмәт карары.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында «Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы РФ Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы.<br>«Өлешле төзелеш өлкәсендәге эшчәнлекне җайга сала торган хокукый механизмнар турында гражданнарга мәгълүмат бирү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» РФ Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 08 августындагы 341 номерлы боерыгы.<br>«Күп фатирлы йортларны төзү өчен акча җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргән гражданнар санына һәм зыян күргән гражданнарның реестрын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | алып бару кагыйдәләренә кертү критерийларын раслау турында» РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының .2016 елның 12 августындгы 560/пр номерллы боерыгы.<br>«Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, күпфатирлы йортка һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектына карата мәгълүматны төзүченең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 9 декабрендәге 914/пр номерлы боерыгы.<br><br>«Проект декларациясе формасын раслау турында» РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы.<br>«Күпфатирлы йортның торак-төзелеш кооперативы тарафыннан төзелеше өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләренең үтәлеше һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күрсәтелгән хисаплылыкны Россия Федерациясе субъектының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органына бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | хуҗалык министрлыгының 2017 елның 3 июлендәге 955/пр номерлы боерыгы.<br>«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).<br><br>«Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан алына торган белешмәләр һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары.<br>«Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | башкаруның административ регламентын раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 12 августындагы 762 номерлы карары |
| 4 | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контроль | «Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Югары Ослан авылы, Медгородок ур., 1, Тел. 2-19-35<br><br>Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, ТКХ, элемтә һәм энергетика бүлеге, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18, тел. 2-23-43 | Россия Федерациясе Җир кодексы.<br><br>Татарстан Республикасы Җир кодексы.<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон.<br><br>«Башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан (алар карамагында бу документлар һәм (яки) мәгълүмат булган оешмалардан (шул исәптән электрон формада, документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары тарафыннан соратып алу һәм алу турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары.<br>«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары, башка дәүләт органнарыннан, җирле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә соратып алына торган һәм (яисә) алына торган документлар исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724 номерлы күрсәтмәсе.<br>Муниципаль берәмлек уставы һәм башка норматив хокукый актлар.<br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы.<br>«Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен билгеләү турында» 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары. |